ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

14 июль 2026 ел | № 6977

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучылар һәм муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр өчен өстәмә социаль ярдәм чаралары турында» 2026 елның 17 мартындагы 2548 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучылар һәм муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр өчен өстәмә социаль ярдәм чаралары турында» 2026 елның 17 мартындагы 2548 номерлы Карарына, 1, 2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«1. Гомуми белем бирү оешмаларында туклану бәясен билгеләргә:

1) бер тапкыр түләүсез туклану:

- 1-4 сыйныф укучылары өчен - 77,76 сум.;
- 5-11 сыйныф укучылары өчен - 92,24 сум.;

2) ике тапкыр түләүсез туклану:

- 1-4 сыйныф укучылары өчен - 134,06 сум.;
- 5-11 сыйныф укучылары өчен - 136,10 сум.;

3) интернат – мәктәпләрдә яшәүче тәрбияләнүчеләр өчен биш тапкыр түләүсез туклану - 236,70 сум.

2. Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның түбәндәге категорияләре өчен түләүсез кайнар ризык билгеләргә:

1) бер тапкыр түләүсез кайнар ризык:

- 1-4 сыйныф укучылары өчен;

- 2) балигъ булмаган өч һәм аннан күбрәк балалы гаиләләрдә тәрбияләнүче 5-11 сыйныф укучылары өчен;

2) ике тапкыр түләүсез кайнар ризык:

- инвалид балалар өчен, сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикле балалар өчен;

- Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсе хезмәткәрләренең, Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсенең федераль дәүләт граждан хезмәткәрләренең, Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсендә эшләүчеләрнең балалары өчен;

- «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Россия милли гвардия гаскәрләренең ведомстводан тыш сак идарәсе» ФДКУ филиалы – Яр Чаллы шәһәре буенча ведомстводан тыш сак бүлеге граждан персоналының, хезмәткәрләренең балалары өчен;

- Сириядән килгән, шул исәптән Россия территориясендә вакытлыча яшеренү урыны алган, Яр Чаллы шәһәрендә вакытлыча урнаштырылган качакларның балалары өчен;

- Татарстан Республикасы буенча Росгвардия идарәсенең Яр Чаллы шәһәре «Тайфун» ОМОН хезмәткәрләренең балалары өчен;

- махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның балалары өчен;

- махсус хәрби операциядә катнашканда яралану сәбәпле дәвалануда булган гражданнарның балалары өчен;

- махсус хәрби операциядә катнашу чорында алган авыру аркасында яки хәрби травма аркасында 1 төркем инвалид булган гражданнарның балалары өчен;

- махсус хәрби операция зонасында һәлак булган яки хәбәрсез югалган гражданнарның балалары өчен.».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» вакытлы матбугат басмаларында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Ф.Ш. Салахов